

Габдулла Тукайның 127 еллыгына багышлана

# Тукай нигезләре





Тукайның берничә нигезенә баш иясе килә. **Беренчесе – Кушлавыч**, Тукай туган нигез.Әтисе, әнисе йорты. \Хәзер Тукайның Кушлавычтагы Музей – йорты булып тора. Ул яңадан торгызыла/.Яшь Габдулланың “сәяхәте”шушы авылдан башлана.

- **Икенче нигез – Кырлай**, Кырлай урманнары, Кырлай табигате, Сәгъди абзый йорты.”Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урын”,-ди шагыйрь үзе. Бу авылның табигате, сабантуйлары күңелен әсир итә.”Шүрәле”, “Су анасы” әкиятләре, ”Туган авыл”, “Туган җиремә”,“Пар ат” шигырьләре дә шунда языла. Монда узган еллары ул соңыннан бик сагынып искә ала.





Сабый Габдулла, ятим Апуш. Дөньяның ачысын – төчесен татып үскән бу моңлы бала олуг шагыйрь булды, халкыбыз күңелендә мәңгегә урын алды.

Шагыйрьләрнең җирдәге тормышы һәрвакыт кайгылы һәм еш кына кыска була. Аларның күңелләре сизгер, тиз җәрәхәтләнүчән һәм ялгыз була - йөрәк әрнүләре гүзәл сүзләр булып ташып чыга.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның гомер юлы нибары 27 генә ел булды.



Өчиле авылының бер урамы.



Кечкенә Габдулла бабасы Зиннәтулла белән Өчиледә

# Нәкъ Казан артында бардыр

# бер авыл- **Кырлай** диләр.



# “Дөньяга күзем ачылган урын”









# Шүрәле асрап яткан карурман



# Кырлайда Г.Тукай музее







# Шигырь бәйрәме





**Тукайга килә халык.**

**Җырларын ятлап күңелдән.**
**Талантына таң калып,**
**Бөек җырчысы янына**
**Тукайга килә халык.**

**Аның белән тел ачылган,**
**Һәр адымда кирәк, бел.**
**Туган тел – Тукай теле ул.**
**Тукай теле – туган тел.**







БУ

РӘСЕМНӘР

КАЙСЫ

шигырьдән













# Тукай әкиятләрендә кунакта







# Бөек Тукаебызны беләсеңме?

- Г. Тукай туган ел.
- 1901 1891 1886
- Тукай кайсы авылда туган?
- Кырлай Өчиле Кушлавыч
-
- Автобиографик повестеның исеме.
- “Г.Тукай” “Исемдә калганнар “Хәтирәләрем”
- Әти - әнисенең исеме.
- Бибимәмдүдә Газизә Мөхәммәтгариф
- Туган көне.
- 26 нчы апрель 26 нчы май 16 нчы апрель
- Өчиледә кем гаиләсенә эләгә?
- Сәгъди Усал карчык Бабасының ишле гаиләсенә
- Кырлай авылы белән кайсы кеше бәйле?
- Газизә Сәгъди Шакир
- «Шүрәле”поэмасында кайсы авыл турында сүз бара?
- Өчиле Сасна Кырлай
- Кечкенә чакта Габдулланы кем дип йөрткәннәр?
- Габди Малай Апуш
- Уральск шәһәре элек ничек аталган?
- Җәйлек Җаек Җиләк